**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**УРТА БАЛТАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

24 апрель, 2023 ел №89

**«Җир салымы турында»гы карарга үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Урта Балтай авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының «Җир салымы турында» 2014 елның 14 декабрендәге 75 номерлы Урта Балтай авыл җирлеге советы карарына, 6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«6. Салым түләүче оешмалар өчен хисап чорлары дип беренче квартал, икенче квартал һәм календарь елның өченче кварталы танылa.».

2. «Җир салымы турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 08 ноябрендәге 73 номерлы Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Урта Балтай авыл җирлеге советы карарына «һәм алдагы салым чорлары» сүзләрен өстәп, үзгәреш кертергә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң (игълан ителгәннән соң) үз көченә керә.

**Урта Балтай авыл**
**җирлеге башлыгы** **И.М.Гараев**